МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.05.2015 Казан ш. № под-5698/15

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе турында**

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында»2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, шулай ук коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны алга таба бетерү максатларында к а р а р б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе расалга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләрен (алга таба – Министрлык) таләпләрне үтәү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү, әлеге боерык белән расланган, өчен җаваплы итеп билгеләп кую, аларны юридик бүлеккә җибәрү һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү тәртибе өчен Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру.

3. Мәгълүмати технологияләрне үстерү һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү бүлегенә (Юнусов Б.М.), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге министрлыкның рәсми сайтында Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, Министрлык тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларны, норматив хокукый актлар проектларын урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Министр в.б.** **А.И.Поминов**

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
06.05.2015 ел, № под-5698/15
боерыгы белән

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында»2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына, шул исәптән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү процедурасын билгели (алга таба-Министрлык)

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның эшләнелә торган норматив хокукый актлары проектларына хокукый экспертиза үткәрү (алга таба - норматив хокукый актлар проектлары) һәм Министрлыкның кабул ителгән норматив хокукый актлары (алга таба - норматив хокукый актлар) мониторингы вакытында үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты-норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза үз көчен югалткан яисә юкка чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

1.5. Министрлыкта норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертизаны оештыруның төп принциплары булып торалар:

1) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру мәҗбүрилеге;

2) башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә норматив хокукый актны бәяләү;

3) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезлелеге, объективлыгы һәм тикшерелүе;

4) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүче затларның компетентлыгы;

5) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә Министрлыкның граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеге.

## II. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә үткәрелә (алга таба - Методика).

2.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (алга таба - министр) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат билгели (алга таба - вазыйфаи зат). Күрсәтелгән вазыйфаи зат шулай ук Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба - Журнал) алып бару өчен җаваплы булып тора (1нче Кушымта).

2.3. Норматив хокукый актны яисә норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлекчә (алга таба - эшләүче) аның вазыйфаи затына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә, бу Журналда аның кергән көнне чагылдырыла.

2.4. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Журналда теркәлгәннән соң биш көн эчендә үткәрелә.

2.5. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат тарафыннан бәяләмә әзерләнә һәм имзалана

Нәтиҗәдә коррупциоген факторлар булу турында (2нче Кушымта) нәтиҗәдә коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган методика нигезендә коррупциоген факторлар чагыла һәм аларны бетерү ысуллары тәкъдим ителә

Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциоген факторлар юк икән, эшләүчегә җибәрелә торган коррупциоген факторларның булмавы турында бәяләмә рәсмиләштерелә (3нче Кушымта).

2.6. Әгәр экспертизага җибәрелгән норматив хокукый акт проектында коррупциоген факторлар юк икән, эшләүче, коррупциоген факторлар булмау турында бәяләмә алгач, норматив хокукый акт проектын, кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләре визалары белән, министрга кул куюга җибәрә.

2.7. Әгәр норматив хокукый актта коррупциоген факторлар ачыкланса, әзерләүчесе, бәяләмә алгач, министр белән килешенеп, аңа үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында яисә аны үз көчен югалткан дип тану турында карар кабул итә.

2.8. Әгәр экспертизага җибәрелгән норматив хокукый акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланган булса, эшләүчесе, коррупциоген факторлар

булу турында бәяләмә алгач, өч көн эчендә барлык җитешсезлекләрне юкка чыгарырга һәм коррупциягә каршы экспертиза өчен вазыйфаи затка эшләп бетерелгән норматив хокукый акт проектын җибәрергә тиеш.

2.9. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына кабат коррупциягә каршы экспертиза өч көн эчендә үткәрелә.

2.10. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылдырыла.

## III. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү тәртибе

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып министрлыкның рәсми басылып чыккан норматив хокукый актлары һәм Министрлык тарафыннан эшләнелә торган, Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган норматив хокукый актлар проектлары тора.

3.2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яки конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелми.

3.3. Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен әзерләүче аны эш көне дәвамында Министрлыкның мәгълүмати технологияләрне һәм куркынычсызлыкны үстерү бүлегенә җибәрә.

3.4. Норматив хокукый акт проектын эшләүчедән кабул ителгән көнгә туры килгән эш көне дәвамында мәгълүмати технологияләрне үстерү һәм куркынычсызлык бүлеге аларны Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда мәгълүмати технологияләрне һәм куркынычсызлыкны үстерү бүлеге эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресы), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтә.

3.6. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылганнан соң җиде эш көне тәшкил итә.

3.7. Норматив хокукый актны, норматив хокукый акт проектын эшләүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәне карый (алга таба - нәтиҗә) һәм аны алганнан соң 15 көн эчендә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка, Бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, мотивлаштырылган җавап җибәрә.

3.8. Норматив хокукый актка, норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар биш көн эчендә эшләүче тарафыннан юкка чыгарыла.

3.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза Бәяләмәсендә бәян ителгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне юкка чыгарганнан соң, эшләүче норматив хокукый

акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне кушып, вазыйфаи затка кабат карауга тапшыра. Кабат карау өч көн эчендә башкарыла.

3.10. Әгәр коррупциоген факторлар норматив хокукый актта ачыкланган булса, эшләүче норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү яки аны үз көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

3.11. Әзерләүченең норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциоген факторлар булуын таныклаучы коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, эшләүче законнарда билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән норматив хокукый актларны, норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үз ризалыгын нигезләп, аңлатма язмасын Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрә.

3.12. Әзерләүченең коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, шул исәптән бәйсез, ул эшләгән проектларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында, коррупциоген факторлар булуын таныклый торган очракта, эшләүче әлеге норматив хокукый актларның проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 1нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын

| № | Актны (акт проекты) экспертиза га кабул итү датасы | Актны (акт проекты) эшләгән структур бүлекчәнең исеме | Актның (акт проекты) исеме | Экспертиза үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре | Структура бүлекчәсе белгече тарафыннан бәяләмә алу һәм аңа кул кую датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 2нче кушымта

**Коррупциоген факторлар булу турында бәяләмә**

__________________________________________________________

(норматив хокукый актның исеме яки норматив хокукый акт проекты исеме)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде

__________________________________________________________

(норматив хокукый актның исеме яки норматив хокукый акт проекты исеме )

анда коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны алга таба бетерү максатларында.

Күрсәтелгән ________________________________________________

(норматив хокукый актның исеме яки норматив хокукый акт проекты исеме)

коррупциоген факторлар ачыкланды ____________________________________

(коррупциоген факторлар төрләре күрсәтелә)

__________________________________________________________

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатларында тәкъдим ителә

__________________________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү ысулы күрсәтелә)

| ____________________ | ________ | __________________ | ________ |
|---|---|---|---|
| (вазыйфаның атамасы) | (имза) | (башлангыч, фамилия) | (дата) |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә 3нче кушымта

**Коррупциоген факторларның булмавы турында бәяләмә**

________________________________________________________________

(норматив хокукый актның исеме яки норматив хокукый акт проекты исеме)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде
________________________________________________________________

(норматив хокукый актның исеме яки норматив хокукый акт проекты исеме )

анда коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны алга таба бетерү максатларында.

Күрсәтелгән ________________________________________________________

(норматив хокукый актның исеме яки норматив хокукый акт проекты исеме)

коррупциоген факторлар ачыкланмады.

| ____________________ | __________ | ____________________ | __________ |
|---|---|---|---|
| (вазыйфаның атамасы) | (имза) | (башлангыч, фамилия) | (дата) |